ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе уставына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2005 елның 3 ноябрендәге 1696-III ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары һәм 2005 елның 3 ноябрендәге 1844-р номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе белән расланган «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе уставына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 11; 2012, № 7 (I өлеш); 2017, № 11), аны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенә аның Уставы үзгәрүгә бәйле рәвештә «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-I номерлы Россия Федерациясе Законында каралган гамәлләрне башкарырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — М.Г. Әхмәтов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2026 елның 8 июне
№ 650-VII ДС

2026 елның 8 июнендәге
650-VII ДС номерлы
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы карарына
кушымта

«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе»
Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе
уставы

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – Редакция) – массакүләм мәгълүмат чарасын – «Ватаным Татарстан» газетасын (алга таба – Газета) әзерләү һәм чыгару максатларында төзелгән коммерциягә карамаган унитар оешма.

Редакциянең тулы исеме: «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе.

Редакциянең кыскартылган исеме: «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» ТР ДБУ.

1.2. Редакцияне гамәлгә куючы һәм аның мөлкәтенең милекчесе – Татарстан Республикасы.

Татарстан Республикасы исеменнән Редакцияне гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (алга таба шулай ук – Гамәлгә куючы) гамәлгә ашыра.

Редакция мөлкәтенең милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Мөлкәт милекчесе) гамәлгә ашыра.

1.3. Редакция эшчәнлеге чикләнмәгән вакытка төзелгән юридик зат булып тора, оператив идарә итү хокукында аңа беркетелгән мөлкәткә, мөстәкыйль баланска, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының территориаль органнарында ачыла торган шәхси счетларга, Россия Федерациясе законнары нигезендә башка счетларга, исеме күрсәтелгән түгәрәк мөһергә, почмакка сугыла торган штампларга һәм башка штампларга, бланкларга, эмблемага ия була һәм үз исеменнән мөлкәти хокуклар һәм мөлкәти булмаган шәхси хокуклар сатып алырга, йөкләмәләр алырга, судларда дәгъвачы һәм җавап бирүче буларак чыгыш ясарга хокуклы була.

1.4. «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-I номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – Массакүләм мәгълүмат чаралары турында закон) 20 статьясындагы дүртенче

өлеше нигезендә әлеге Устав бер үк вакытта Редакциянең һәм Газетаның уставы булып тора.

1.5. Газетаны гамәлгә куючылар – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты исеменнән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты исеменнән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (алга таба шулай ук – Газетаны гамәлгә куючылар).

1.6. Әлеге Устав һәм аңа үзгәрешләр Гамәлгә куючы тарафыннан раслана. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы әлеге Уставны Газета уставы буларак раслый.

1.7. Редакциянең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре.

1.8. Редакциянең вәкиллекләре һәм филиаллары юк.

## 2. Редакция эшчәнлегенең предметы, максатлары һәм төрләре

2.1. Редакция эшчәнлегенең предметы – Редакциянең устав максатларына ирешү өчен турыдан-туры юнәлдерелгән эшләрне башкару.

2.2. Редакция эшчәнлегенең максатлары – Татарстан Республикасы халкы мәнфәгатьләренә кагылучы, иҗтимагый әһәмиятле белешмәләрдән торган хәбәрләрне һәм материалларны Газетада һәм аның электрон версиясендә бастырып чыгару юлы белән Газетаны әзерләү һәм чыгару.

2.3. Редакция эшчәнлегенең төп төре – нәшрият эшчәнлеген гамәлгә ашыру.

2.4. Эшчәнлекнең төп төре нигезендә Редакция законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт заданиесе кысаларында норматив хокукый актларның тулы текстларын кәгазьдә һәм электрон рәвештә бастырып чыгару буенча дәүләт эшен башкара.

2.5. Максатларга ирешү өчен Редакция түбәндәге функцияләрне башкара:

Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең сәяси, иҗтимагый, икътисадый һәм мәдәни тормышы турында мәгълүматны тарату максатларында Газетаны чыгару һәм тарату;

Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары актларын һәм рәсми хәбәрләрен рәсми бастырып чыгару;

Газетаның электрон версиясен чыгару.

2.6. Редакция өчен дәүләт заданиесе Гамәлгә куючы тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә әлеге Уставта каралган Редакция эшчәнлегенең төп төре нигезендә төзелә һәм раслана.

Редакция дәүләт заданиесен үтәүдән баш тартырга хокуксыз.

2.7. Редакция законнар нигезендә эшчәнлекнең керем китерә торган төп булмаган түбәндәге төрләрен гамәлгә ашыра:

китаплар, журналлар һәм башка басма материаллар җыю, брошюралау, төпләү, аларга дизайн ясау һәм аларны биткә салу;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайтлар һәм социаль челтәрләрдә битләр (берләшмәләр) булдыру һәм аларга ярдәм итү;

журналистика, редакцияләү, әдәби иҗат яисә нәшрият эшчәнлегенең башка юнәлешләре буенча курслар, семинарлар һәм мастер-класслар үткәрү;

нәшрият хезмәтләре күрсәтү (гражданнарга һәм оешмаларга аларның материалларын нәшер итүдә ярдәм итү, корректураны, редакцияләүне, биткә салуны һәм басмага әзерләүне дә кертеп);

реклама һәм консалтинг хезмәтләре күрсәтү;

китаплар, басма продукция, шулай ук сувенирлар һәм канцелярия товарлары кебек нәшрият эшчәнлеге белән бәйле товарлар сату;

басма массакүләм мәгълүмат чаралары әзерләү һәм чыгару (Массакүләм мәгълүмат чаралары турында закон нигезендә басма массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясе функциясен гамәлгә ашыру).

2.8. Әгәр эшчәнлекнең аерым төрләре законнар нигезендә лицензияләнергә тиеш булса, Редакция тиешле лицензия алганнан соң мондый эшчәнлек төрләрен башкарырга мөмкин.

2.9. Редакция әлеге Уставта каралмаган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырырга хокуксыз.

## 3. Редакциянең хокуклары һәм бурычлары

3.1. Редакция үз эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

юридик һәм физик затлар белән законнарга, шулай ук Редакция эшчәнлеге максатларына каршы килми торган шартнамәләр төзергә;

үз бурычларын гамәлгә ашыру өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә оешмаларны (дәүләт һәм коммерция), шулай ук шартнамә нигезендә чит оешмалар белгечләрен һәм экспертларын җәлеп итәргә;

массакүләм мәгълүмат чарасын гамәлгә куючы сыйфатында булырга;

Газета исемен кулланырга;

Газетага кушымталарның һәм Газетаның махсус чыгарылышларының исемнәрен билгеләргә;

Газетаны гамәлгә куючылар тарафыннан расланган тематика, массакүләм мәгълүмат чарасының белгечлеге һәм юнәлеше кысаларында үз эшчәнлеген планлаштырырга, аның эчтәлеге һәм сәнгати бизәлеше мәсьәләләрен хәл итәргә;

Редакция штатында тормаган иҗади һәм техник хезмәткәрләрне аерым биремнәр үтәү өчен җәлеп итәргә;

билгеләнгән тәртиптә Газета аудиториясе белән язышуны гамәлгә ашырырга, Газетаны укучыларның мәнфәгатьләрен һәм тәкъдимнәрен исәпкә алырга;

законнар нигезендә дәүләт органнары һәм оешмалары, иҗтимагый берләшмәләр, аларның вазыйфаи затлары эшчәнлеге турында мәгълүмат соратырга һәм шушы гарызнамәләргә җаваплар алырга;

Газетаны гамәлгә куючылар белән килештермичә Газетада хәбәрләр һәм материаллар урнаштырырга, нинди дә булса вакыйгаларга һәм фактларга бәя бирергә, үз фикерен белдерергә, бәхәскә керергә;

законнар нигезендә үз журналистларын аккредитацияләүне гамәлгә ашырырга.

3.2. Редакция түбәндәге бурычларны үтәргә тиеш:

расланган дәүләт заданиесен тулы күләмдә башкарырга;

Газета эшчәнлеген матди-техник тәэмин итәргә;

Редакциянең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын төзергә һәм Гамәлгә куючы билгеләгән тәртиптә аңа раслауга тәкъдим итәргә;

Гамәлгә куючыга үз эшчәнлеге һәм Редакциягә беркетелгән мөлкәттән файдалану турында Гамәлгә куючы билгеләгән тәртиптә төзелә һәм раслана торган хисап тапшырырга;

Гамәлгә куючыга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бухгалтерлык һәм статистика хисабы тапшырырга;

Мөлкәт милекчесенә мөлкәттән билгеләнгән тәртиптә файдалану турында хисап тапшырырга;

конфиденциаль характердагы мәгълүматны (персональ белешмәләрне дә кертеп) яклауны тәэмин итәргә;

архив документларын (даими саклanudагы һәм шәхси состав буенча) исәпкә алуны, аларның сакланышын һәм алардан файдалануны, шул исәптән гражданнарны социаль яклауга бәйле архив документларын бирүне һәм Редакцияне үзгәртеп корганда яисә бетергәндә билгеләнгән тәртиптә аларны архив учреждениеләренә вакытында тапшыруны, тәэмин итәргә;

билгеләнгән таләпләр нигезендә эш башкаруны оештыруны һәм алып баруны тәэмин итәргә;

Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән гарантияләрне үтәп, Редакция хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләргә;

Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары актларын рәсми бастырып чыгаруны гамәлгә ашырырга;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Рәисенең, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының һәм аның Президиумының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, аларның таләбе буенча, рәсми

хәбәрләрен һәм законнар нигезендә Газетада бастырып чыгару каралган башка материалларны бастырып чыгарырга;

Газета аша бастырып чыгару таләбе булган законлы көченә кергән суд карарларын түләүсез һәм билгеләнгән вакытта бастырып чыгарырга;

Газетаның эшчәнлегенә кагылышлы Газетаны теркәгән органнан кергән хәбәрне түләүсез һәм билгеләнгән вакытта бастырып чыгарырга;

Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеге турында Газета аша халыкка оператив мәгълүмат бирергә;

мәгълүмат чыганагын сер итеп сакларга һәм белешмәне үз исемен фаш итмәү шарты белән биргән затны атамаска, моңа суд производствосында булган эшкә бәйле рәвештә судтан тиешле таләп килгән очрак керми;

таратыла торган хәбәрләрдә һәм материалларда балигъ булмаганга кагылышлы һәм Массакүләм мәгълүмат чаралары турында закон нигезендә урнаштыру (тарату) рөхсәт ителми торган белешмәләрне (мәгълүматны) фаш итмәскә;

файдаланыла торган әсәрләргә хокукларны, авторлык хокукларын һәм интеллектуаль милеккә башка хокукларны да кертеп, сакларга;

законнар нигезендә массакүләм мәгълүмат чарасын бастырып чыгару белешмәләрен урнаштырырга;

конфиденциаль характердагы мәгълүматтан файдалану кагыйдәләрен үтәргә.

3.3. Редакция түбәндәгеләргә хокуксыз:

таратыла торган хәбәрләрдә һәм материалларда гражданнар тарафыннан сер итеп саклау шарты белән бирелгән белешмәләрне фаш итәргә;

мәгълүмат чыганагын фаш итәргә һәм белешмәне үз исемен фаш итмәү шарты белән биргән затны атарга, моңа суд производствосында булган эшкә бәйле рәвештә судтан тиешле таләп килгән очрак керми;

таратыла торган хәбәрләрдә һәм материалларда җинаять кылган йә аны кылуда шикләнелә торган, шулай ук административ хокук бозу яисә җәмгыятькә каршы гамәл кылган балигъ булмаганның шәхесенә турыдан-туры яисә читләтеп күрсәтә торган мәгълүматны балигъ булмаган затның һәм аның законлы вәкиленең ризалыгыннан башка фаш итәргә;

таратыла торган хәбәрләрдә һәм материалларда Массакүләм мәгълүмат чаралары турында законның 4 статьясындагы алтынчы өлешендә күрсәтелгән мәгълүматны фаш итәргә, моңа шундый мәгълүматны тарату хокукка каршы гамәлләр кылу (гамәл кылмау) аркасында зыян күргән балигъ булмаган затның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында башкарылган очраклар керми.

3.4. Редакция Россия Федерациясе законнарын һәм Татарстан Республикасы законнарын бозган өчен җаваплы.

4. Редакциянең мөлкәте һәм финанс белән тәэмин ителеше

4.1. Редакция мөлкәте аңа оператив идарә итү хокукында беркетелә. Редакциягә төп эшчәнлеген башкару өчен кирәкле җир кишәрлеге аңа даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирелә.

4.2. Редакция аңа оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәткә карата үзенең эшчәнлек максатлары һәм мөлкәтнең билгеләнеше нигезендә законнарда билгеләнгән чикләрдә биләү, аннан файдалану хокукын гамәлгә ашыра һәм, законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, Мөлкәт милекчесе ризалыгы белән бу мөлкәт белән эш итә.

Редакция мөлкәте Татарстан Республикасы милке була.

Мөлкәт милекчесе артык булган, файдаланылмый торган яисә билгеләнеше буенча файдаланылмый торган мөлкәтне кире алырга һәм аның белән үзе теләгәнчә эш итәргә хокуклы.

4.3. Редакция үз йөкләмәләре буенча үзенең оператив идарә итү хокукында булган барлык мөлкәте, Редакциягә Мөлкәт милекчесе тарафыннан беркетелгән яисә Редакция Гамәлгә куючы тарафыннан бүлеп бирелгән акчаларга сатып алган аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәттән, шулай ук күчемсез мөлкәттән тыш, Мөлкәт милекчесе тарафыннан аңа беркетелгән мөлкәт белән дә, керем китерә торган эшчәнлектән алынган керемнәр исәбенә сатып алынган мөлкәт белән дә җавап бирә.

Мөлкәт милекчесе, законнарда һәм әлеге Уставта билгеләнгән очраклардан тыш, Редакция йөкләмәләре буенча җаваплы булмый.

Редакциянең гражданнарга зыян китерүгә бәйле йөкләмәләре буенча, Редакциядә түләтү өчен тотылырга мөмкин мөлкәт җитәрлек булмаса, Мөлкәт милекчесе субсидиар җаваплылыкка ия була.

Редакция бетерелгән очракта, Редакциянең әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә түләтү өчен тотылырга мөмкин булган мөлкәте җитәрлек булмаганда, Редакциянең гавами шартнамәдә күрсәтелгән йөкләмәләре буенча Мөлкәт милекчесе субсидиар җаваплылыкка ия була.

4.4. Редакциянең Мөлкәт милекчесе тарафыннан Редакциягә беркетү турында карар кабул ителгән мөлкәт белән оператив идарә итү хокукы, законда, башка хокукый актларда яисә Мөлкәт милекчесе карарында башкасы билгеләнмәгән булса, мөлкәт тапшырылган көннән барлыкка килә.

Редакциянең оператив идарәсендәге мөлкәттән файдаланудан продукция һәм керемнәр, шулай ук ул шартнамә яисә башка нигезләр буенча сатып алынган мөлкәт Редакциягә Россия Федерациясе Граждан кодексында һәм башка законнарда билгеләнгән тәртиптә керә.

Редакциягә аңа беркетелгән мөлкәтне читләштерү яисә мөлкәткә хокукны чикләп торуга китерә торган алыш-бирешләр башкару тыела.

4.5. Редакция Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының территориаль органнарында законнарда

билгеләнгән тәртиптә ачыла торган шәхси счетлар аша законнар нигезендә керә торган акчалар белән эш итү операцияләрен гамәлгә ашыра.

4.6. Редакция керем китерә торган эшчәнлек белән үзенең төзелү максатларына ирешергә мөмкинлек бирә һәм бу максатларга туры килә торган эшчәнлек булганга күрә генә шөгыльләнергә хокуклы. Күрсәтелгән эшчәнлектән алынган керемнәр һәм шушы керемнәр исәбенә сатып алынган мөлкәт белән Редакция мөстәкыйль эш итә.

4.7. Редакция мөлкәтен булдыру һәм аны финанслау чыганаклары түбәндәгеләр:

дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә, эшләр башкаруга дәүләт заданиесен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә бәйле максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр;

дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә, эшләр башкаруга дәүләт заданиесен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган максатларга бирелгән субсидияләр;

Мөлкәт милекчесе тарафыннан оператив идарәгә тапшырылган мөлкәт;

әлеге Устав нигезендә гамәлгә ашырыла торган керем китерүче эшчәнлектән алынган акчалар;

ирекле мөлкәт кертемнәре һәм иганәләр;

законнарда каралган башка чыганаклар.

4.8. Федераль законнарда башкасы каралмаган булса, Редакция кредит оешмаларында депозитларга акча салырга, шулай ук кыйммәтле кәгазьләр белән алыш-бирешләр башкарырга хокуксыз.

4.9. Редакция аңа Мөлкәт милекчесе тарафыннан беркетелгән яисә Гамәлгә куючы аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт сатып алуга бүлеп биргән акчалар исәбеннән Редакция тарафыннан сатып алынган шундый мөлкәт, шулай ук күчемсез мөлкәт белән Мөлкәт милекчесенең ризалыгыннан башка эш итәргә хокуксыз.

4.10. Редакциянең дәүләт заданиесен үтәвен финанс белән тәэмин итү күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Редакция Гамәлгә куючы билгеләгән срокларда ел саен Редакциягә беркетелгән яисә Гамәлгә куючы күчемсез мөлкәт һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт сатып алуга бүлеп биргән акчалар исәбеннән сатып алынган мондый мөлкәтне карап тотуга чыгымнарның, салым салу объекты буларак танылган тиешле мөлкәткә, шул исәптән җир кишәрлекләренә, салымнар түләүгә чыгымнарның исәп-хисабын Гамәлгә куючыга тапшыра.

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Редакциягә башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирелергә мөмкин.

4.11. Редакция Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына кертү өчен мөлкәт турында белешмәләрне билгеләнгән тәртиптә тапшырырга тиеш.

4.12. Редакция эре алыш-бирешләрне һәм башкарылуында кызыксыну булган алыш-бирешләрне Гамәлгә куючы белән алдан килештереп кенә башкара. «Эре алыш-биреш» һәм «башкарылуында кызыксыну булган алыш-биреш» төшенчәләре «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законда кулланыла торган төшенчәләргә туры килә.

## 5. Эшчәнлекне оештыру һәм Редакция белән идарә итү

5.1. Редакция белән идарә итү законнар һәм әлеге Устав нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2. Редакция белән идарә итү өлкәсендә Гамәлгә куючы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

дәүләт заданиесен раслау, дәүләт заданиесен үзгәртү турында карар кабул итү;

Редакциянең дәүләт заданиесен үтәвен финанс белән тәэмин итүне гамәлгә ашыру;

Редакциянең эре алыш-бирешләрен һәм башкарылуында кызыксыну булган алыш-бирешләрне алдан килештерү;

Редакциянең оператив идарәсендәге күчемсез мөлкәт һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт белән алыш-бирешләрне килештерү һәм Редакциянең мөлкәтен, Редакциягә беркетелгән яисә Гамәлгә куючы аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт сатып алуга бүлеп биргән акчалар исәбеннән сатып алынган мондый мөлкәттән, шулай ук күчемсез мөлкәттән тыш, гамәлгә куючысы яисә катнашучысы булып торган коммерциягә карамаган оешмаларга тапшыру турындагы мөрәҗәгатьләрен карау;

гамәлгә куючысы яисә катнашучысы булып торган коммерциягә карамаган оешмаларга Редакция тарафыннан акчалар тапшыруны килештерү турында карарлар кабул итү;

Редакциягә беркетелгән аеруча кыйммәтле мөлкәт төрләрен билгеләү;

законнарда каралган башка мәсьәләләрне хәл итү.

5.3. Мөлкәт милекчесе компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Редакция уставы проектын һәм аңа үзгәрешләр кертүне килештерү;

мөлкәтне оператив идарә хокукында Редакциягә беркетү;

түбәндәге карарларны кабул итү:

Редакциягә беркетелгән объектларны аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт составыннан чыгару турында;

Редакциянең оператив идарәсендәге күчемсез мөлкәт һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт белән алыш-бирешләрне килештерү турында;

Редакциянең мөлкәтен, Редакциягә беркетелгән яисә Гамәлгә куючы аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт сатып алуга бүлеп биргән акчалар исәбеннән сатып алынган мондый мөлкәттән, шулай ук күчемсез мөлкәттән тыш, гамәлгә куючысы яисә катнашучысы булып торган коммерциягә карамаган оешмаларга тапшыруны килештерү турында;

Редакциягә беркетелгән артык булган, файдаланылмый яисә билгеләнеше буенча файдаланылмый торган мөлкәтне йә Гамәлгә куючы мөлкәт сатып алуга бүлеп биргән акчалар исәбеннән Редакция тарафыннан сатып алынган мондый мөлкәтне тартып алу турында;

кредиторлар таләпләре канәгатьләндерелгәннән соң калган Редакция мөлкәтеннән, шулай ук федераль законнар нигезендә Редакция йөкләмәләре буенча түләтү өчен тотылырга мөмкин булмаган мөлкәттән алга таба файдалану турында;

Редакция эшчәнлеген үз компетенциясе кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә тикшереп торуны гамәлгә ашыру.

## 6. Эшчәнлекне оештыру һәм Газета белән идарә итү

6.1. Газетаны Гамәлгә куючылар түбәндәгеләргә хокуклы:

Редакция белән килештереп, Газетаның исемен үзгәртергә;

Редакция эшчәнлеге турында мәгълүмат алырга;

Редакциягә Газетада бушлай һәм алар күрсәткән срокта алар исеменнән хәбәр яисә материал урнаштыру бурычын куярга;

законнарны бозган очракта Газета эшчәнлеген туктатып торырга;

үз хокукларының һәм бурычларының бер өлешен Редакция ризалыгы белән өченче затка тапшырырга;

массакүләм мәгълүмат чаралары турында Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокукларны гамәлгә ашырырга;

массакүләм мәгълүмат чарасының тематикасын, махсуслашуын һәм юнәлешен расларга.

6.2. Газетаны Гамәлгә куючыларның бурычлары:

әлеге Устав нигезләмәләрен үтәргә;

Редакцияне билгеләнгән тәртиптә кирәкле мәгълүмат белән, шул исәптән аның журналистларын аккредитацияләү, утырышлар, киңәшмәләр һәм башка чаралар турында алдан хәбәр итү юлы белән, тәэмин итәргә;

Массакүләм мәгълүмат чаралары турында законда һәм әлеге Уставта каралган очраклардан тыш, Редакция эшчәнлегенә катышмаска;

Редакцияне Газетада басылып чыгарга тиешле рәсми документлар һәм материаллар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә;

билгеләнгән тәртиптә Редакциянең дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеге турында мәгълүматны тоткарлыксыз, оператив алуына ярдәм итәргә.

6.3. Газетаны Гамәлгә куючыларның мәнфәгатьләрен килештерү һәм алар компетенциясенә кертелгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен Гамәлгә куючылар советы төзелә, анда Газетаны Гамәлгә куючылардан һәркайсыннан дүртәр кеше керә. Гамәлгә куючылар советындагы вәкилләр турындагы карарлар Татарстан Республикасы Дәүләт Советының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының хокукый актлары белән рәсмиләштерелә.

6.4. Гамәлгә куючылар советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

Газетаның үсеш концепциясен һәм стратегиясен раслау;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты фикер алышуына уставны, Газета эшчәнлегенә кагылышлы башка хокукый актларны үзгәртү турында тәкъдимнәр кертү;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты фикер алышуына баш мөхәррир (директор) кандидатурасы турында тәкъдимнәр кертү.

6.5. Гамәлгә куючылар советы аның составының кимендә өчтән икесе булганда мәсьәләләрне хәл итәргә хокуклы. Карар Гамәлгә куючылар советының шунда булган барлык әгъзалары ризалыгы белән кабул ителә. Гамәлгә куючылар советы җыелышында киңәш бирү тавышы хокукы белән баш мөхәррир (директор) катнаша.

## 7. Баш мөхәррир (директор)

7.1. Редакцияне баш мөхәррир (директор) җитәкли.

7.2. Баш мөхәррир (директор) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары белән вазыйфага билгеләнеп куела һәм вазыйфасыннан азат ителә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты баш мөхәррирне (директорны) дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесе һәм Газета редакциясен җитәкләүче зат итеп билгеләп куя.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы баш мөхәррирне (директорны) Газета редакциясен җитәкләүче зат итеп билгеләп куя.

7.3. Баш мөхәррир (директор) вазыйфага Гамәлгә куючылар советы тәкъдиме белән билгеләнә. Баш мөхәррир (директор) вазыйфасына кандидатура «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы тарафыннан Гамәлгә куючылар советы каравына кертелә.

7.4. Баш мөхәррир (директор), мөстәкыйль хәл итеп, Редакция һәм Газета эшчәнлегенә агымдагы җитәкчелекне гамәлгә ашыра, моңа законнарда, әлеге

Уставта Газетаны Гамәлгә куючы, Гамәлгә куючылар, Мөлкәт милекчесе компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр керми.

7.5. Баш мөхәррир (директор) компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

оештыру-хокукый рәвешенә һәм кайсы ведомство карамагында булуга карамастан, Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтәге барлык органнарда һәм оешмаларда Редакция һәм Газета мәнфәгатьләрен яклау;

законнар нигезендә граждан-хокук шартнамәләре (контрактлары) һәм килешүләр төзү;

Редакция һәм Газета компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча документларга кул кую;

ышанычнамәләр бирү;

Редакциянең штат расписаниесен, Редакция хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турындагы нигезләмәләрне раслау;

Редакциянең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын раслау;

Редакциянең еллык бухгалтерлык хисабын раслау;

Редакциянең шәхси счетларындагы акчалар белән эш итү;

Редакция һәм Газета эшчәнлеген регламентлаштыра торган эчке документларны раслау;

Редакция хезмәткәрләрен эшкә алу, вазыйфага билгеләү һәм эштән азат итү;

Редакция хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләрен раслау;

законнарда билгеләнгән тәртиптә Редакция хезмәткәрләрен һөнәри әзерләүне, яңадан әзерләүне һәм аттестацияләүне тәэмин итү;

Редакция хезмәткәрләрен бүләкләү һәм аларны дисциплинар җаваплылыкка тарту;

Редакциянең барлык хезмәткәрләре тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиешле боерыклар, карарлар, күрсәтмәләр чыгару;

Гамәлгә куючылар советына еллык планны һәм Редакция һәм Газета эшчәнлеге турында еллык хисапны тәкъдим итү;

Газетаны әзерләү, чыгару һәм тарату мәсьәләләре буенча ахыргы карарны кабул итү;

Газета һәм Редакция журналистларын һәм хезмәткәрләрен иҗади һәм һөнәри уңышлар өчен бүләкләүгә тәкъдим итү;

Газетада урнаштыру өчен материалларны раслау;

Газета рубрикаларын булдыру һәм бетерү;

материалларны бастырып чыгаруга рөхсәт бирү, шулай ук аларны редакцияләү һәм бетерү;

карауга тәкъдим ителә торган материалларны (хәбәрләрне) хуплау яисә кире кагу турында карарлар кабул итү, авторлар, редакторлар һәм Редакциянең башка хезмәткәрләре арасында фикер төрлелеген җайга салу;

законнар, әлеге Устав белән аның компетенциясенә караган башка мәсьәләләрне хәл итү.

7.6. Баш мөхәррир (директор) законнар нигезендә Редакция һәм Газета эшчәнлеге өчен җаваплы була.

## 8. Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм аны җайга салу

8.1. Мәнфәгатьләр конфликты дигәндә, Редакция хезмәткәренең шәхси кызыксынуы аның тарафыннан хезмәт бурычларын тиешлечә үтәүгә йогынты ясарга мөмкин булган һәм шуның нәтиҗәсендә Редакция хезмәткәренең шәхси кызыксынуы белән аның хезмәткәре булган Редакциянең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасында Редакция мөлкәтенә һәм (яисә) аның эшлекле репутациясенә зыян китерергә сәләтле каршылык барлыкка килгән яисә барлыкка килергә мөмкин булган вазгыять аңлашыла.

8.2. Редакция хезмәткәре тарафыннан хезмәт бурычларын тиешлечә үтәүгә йогынты ясый торган яисә ясарга мөмкин булган аның шәхси кызыксынуы дигәндә, Редакция хезмәткәре тарафыннан хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә акчалар, кыйммәтле әйберләр, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәти хокуклар, яисә үзе яисә өченче затлар өчен мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтүләр рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге аңлашыла.

8.3. Баш мөхәррир (директор) вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында Гамәлгә куючыга хәбәр итәргә тиеш.

8.4. Редакция хезмәткәре вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында баш мөхәррирга (директорга) хәбәр итәргә тиеш. Баш мөхәррирга (директорга) хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрдәге белешмәләр исемлеге, бу белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибе баш мөхәррир (директор) тарафыннан билгеләнә.

8.5. Баш мөхәррир (директор) вазыйфасына килүче зат (эшкә кергәндә) һәм баш мөхәррир (директор) үзенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тапшырырга тиеш.

## 9. Журналистлар – Редакциянең штаттагы хезмәткәрләре коллективы вәкаләтләре

9.1. Журналистлар – Редакциянең штаттагы хезмәткәрләре коллективын (алга таба – журналистлар коллективы) Редакция белән хезмәт шартнамәсе нигезендә Газета өчен хәбәрләрне һәм материалларны (текстлы һәм сурәтле) редакцияләүне (әдәби, фәнни, сәнгати, техник), булдыруны, җыюны яисә әзерләүне гамәлгә ашыручы затлар тәшкил итә.

9.2. Журналистлар коллективы үз эшчәнлеген һөнәри мөстәкыйльлек нигезендә һәм Массакүләм мәгълүмат чаралары турында законга таянып гамәлгә ашыра.

9.3. Журналистлар түбәндәгеләргә хокуклы:

мәгълүматны эзләргә, соратып алырга, алырга һәм таратырга;

дәүләт органнарында һәм оешмаларында, предприятиеләрдә һәм учреждениеләрдә, иҗтимагый берләшмәләр органнарында йә аларның матбугат хезмәтләрендә булырга;

мәгълүмат соратып алуга бәйле рәвештә вазыйфаи затлар тарафыннан кабул ителергә;

документлардан һәм материаллардан, аларның дәүләт серен, коммерциячел серне яисә закон белән махсус саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләр булган фрагментларыннан тыш, файдалана алырга;

файдаланыла торган хезмәтләргә хокукларны, авторлык хокукларын, нәшрият хокукларын, интеллектуаль милеккә башка хокукларны да кертеп, үтәү шарты белән документларның һәм материалларның күчермәләрен алырга, аларны бастырырга, игълан итәргә яисә башка ысул белән кабат булдырырга;

законнарда каралган очраклардан тыш, язмалар, шул исәптән аудио- һәм видеотехника, кинога һәм фотога төшерү чараларыннан файдаланып, булдырырга;

табигать бәла-казалары, аварияләр һәм һәлакәтләр, массакүләм тәртипсезлекләр булган һәм гражданнар күпләп җыелган махсус сакланыла торган урыннарда, шулай ук гадәттән тыш хәл игълан ителгән урыннарда булырга, митингларда һәм демонстрацияләрдә булырга;

хәбәр ителә торган мәгълүматның дөреслеген тикшерергә;

үз имзасы белән тарату өчен билгеләнгән хәбәрләрдә һәм материалларда шәхси фикерләрен һәм бәяләмәләрен бәян итәргә;

инануларына каршы килә торган хәбәрне яисә материалны үз имзасы белән әзерләүдән баш тартырга;

редакцион әзерләү барышында эчтәлеге, аларның фикеренчә, бозылган хәбәргә яисә материалга имза салмаска, йә бу хәбәрне яисә материалны

куллануны тыярга яисә аны башкача куллану шартларын һәм характерын алдан килештерергә;

алар тарафыннан әзерләнгән хәбәрләрне һәм материалларны үз имзасы белән, псевдоним белән яисә имзасыз таратырга;

массакүләм мәгълүмат чаралары турында Россия Федерациясе законнары белән бирелгән башка хокуклардан файдаланырга.

9.4. Журналистлар түбәндәгеләргә бурычлы:

әлеге Уставны үтәргә;

алар тарафыннан хәбәр ителә торган мәгълүматның дөреслеген тикшерергә;

мәгълүмат биргән затларның аның чыганагын күрсәтү турында, шулай ук, әгәр өземтә итеп китерелә торган фикер беренче мәртәбә игълан ителсә, аны авторлаштыру үтенечләрен канәгатьләндерергә;

мәгълүматның һәм (яисә) аның чыганагының конфиденциальлеген сакларга;

массакүләм мәгълүмат чарасында гражданның шәхси тормышы турында белешмәләр таратуга гражданның яисә аның законлы вәкилләренең ризалыгын алырга (җәмгыять мәнфәгатьләрен яклау өчен кирәк булган очраклардан тыш);

гражданнардан һәм вазыйфаи затлардан мәгълүмат алганда, аудиога һәм видеога яздыруны, киногa һәм фотога төшерүне үткәрү турында аларга хәбәр итәргә;

алар тарафыннан әзерләнгән хәбәрне яисә материални таратуга бәйле рәвештә ихтимал булган дәгъвалар турында һәм законда каралган башка таләпләрне куюю хакында баш мөхәрриргә (директорга) хәбәр итәргә;

баш мөхәррир (директор) яисә Редакция тарафыннан бирелгән биремнән, әгәр ул йә аны үтәү законны бозуга бәйле булса, баш тартырга;

һөнәри эшчәнлекне гамәлгә ашырганда, беренче таләп буенча редакция таныклыгын яисә журналистның шәхесен һәм вәкаләтләрен таныклаучы башка документны күрсәтергә;

һөнәри эшчәнлекне гамәлгә ашырганда, алар тарафыннан сайлау алды агитациясен, референдум мәсьәләләре буенча агитация үткәрүгә тыюны үтәргә;

массакүләм мәгълүмат чаралары турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка бурычларны үтәргә.

9.5. Журналистлар коллективы редакция планнарын эшләүдә һәм әзерләүдә катнаша, баш мөхәрриргә (директорга) Газетаның сыйфатын яхшырту һәм редакция-нәшрият процессын тизләтү буенча тәкъдимнәр кертә.

9.6. Массакүләм мәгълүмат чаралары турында законның 20 статьясы нигезендә әлеге Устав журналистлар коллективы тарафыннан кабул ителә.

## 10. Исемгә хокукны тапшыру яисә саклап калу. Газетаны гамәлгә куючылар составын үзгәртүнең юридик нәтиҗәләре

10.1. Газетаны теркәгәндә белдерелгән исем белән аны чыгару хокукына Газетаны гамәлгә куючылар ия була.

10.2. Газетаны гамәлгә куючылар составы үзгәргән очракта, исемгә хокук яңа гамәлгә куючылар составына (гамәлгә куючыга) күчә.

10.3. Исемгә хокукны күчерү, массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турындагы язмага үзгәрешләр кертеп, теркәү органына тиешле гариза бирү юлы белән беркетелә.

10.4. Газетаны гамәлгә куючылар составы үзгәргән очракта, Газетаны чыгару законда билгеләнгән тәртиптә массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турындагы язмага үзгәрешләр кертелгәннән соң гамәлгә ашырыла.

10.5. Газетаны гамәлгә куючыларның берсе үзгәртеп корылган очракта, аның хокуклары һәм бурычлары тулы күләмдә хокук дәвамчысына күчә. Газетаны гамәлгә куючылар бетерелгән очракта аның эшчәнлеге туктатыла.

## 11. Редакцияне үзгәртеп кору һәм бетерү тәртибе

Редакцияне үзгәртеп кору һәм бетерү Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә Гамәлгә куючы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 12. Газета эшчәнлеген туктату һәм туктатып тору тәртибе

12.1. Газета эшчәнлеген туктату һәм туктатып тору нигезләре һәм тәртибе Массакүләм мәгълүмат чаралары турында законның 16 статьясы белән билгеләнә.

12.2. Газетаны гамәлгә куючылар Газета эшчәнлеген түбәндәге очракларда туктатырга һәм туктатып торырга хокуклы:

Редакция тарафыннан Газетаны гамәлгә куючыларның кисәтүен алганнан соң кабат массакүләм мәгълүмат чаралары турында законнар, әлеге Устав таләпләре бозылганда;

Гамәлгә куючы Газета чыгаруны финанслау мөмкинлеген югалтканда;

Газетаны әзерләү һәм чыгару Газетаны гамәлгә куючылар тарафыннан башка нигезләр буенча максатчан түгел дип танылганда.

12.3. Газетаны гамәлгә куючылар тарафыннан аның эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү әлеге Уставны Газетаның эшчәнлеге өлешендә гамәлдән чыгаруга китерә.

12.4. Газетаны гамәлгә куючыларның Газета эшчәнлеген туктатып тору яисә туктату турындагы карары мондый карар кабул ителгән көненнән алып

бер ай эчендә Массакүләм мәгълүмат чаралары турында законның 11 статьясы нигезендә теркәү органына җибәрелә.